**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ УЛЬЯНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423115, Ульяновка село, Центральная ул., 44 дом тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17 email: Ul.Cmn2@tatar.ru 423115, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 44 йорт

**№ 06** **08 август 2024 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Ульяновка авыл
җирлеге Башкарма комитетының
«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка
чыгару буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында»
2021 елның 30 июлендәге 13 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 10 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Гариза белән «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслашу объекты булган тиешле күчемсез мөлкәт объектына карата кадастр эшләрен яисә комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.2. 1.5 пунктның 9,10 абзацларын яңа редакциядә бәян итәргә «Планлаштыру структурасының элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, бакчачылык,

яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренең урнашу территорияләре;

урам-юл челтәренең элементы-урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар».

1.3. 2.3.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә «2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын юкка чыгару турындагы карар берләштерелә».

1.4. 2.4 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә «2.4. Адреслашу объектына адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару турында карар кабул итү, адреслашу объектына адрес бирүдән яисә аның адресын юкка чыгарудан баш тарту турында карарлар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле белешмәләрне дәүләт адреслар реестрында урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла:

а) гариза кәгазьдә бирелгән очракта - гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта - гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Шәмсетдинов С.З.